**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлеге Чукмарлы авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

**2024 ел, 19 ноябрь** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә "2024 елнын 19 ноябрендә узган гражданнар жыенынын" "Сез 2025 елда һәр балигъ булган кешедән 500,00 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә килешэсезме?" мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Чукмарлы авыл җирлеге Чукмарлы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән моннан тыш, вакытлы хәрби хезмәт узучы, махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаилә әгъзаларыннан, 1 Төркем инвалидларыннан, көндезге уку йортлары студентларыннан тыш, алынган акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итәргә жибәру очен узарасалым кертергэ килешэсезме:

1)Чукмарлы торак пунктында урамнарда яктырту җайланмасы (лампаларны, энергияне сак тотучы тотучы яктырткычларны сатып алу һәм урнаштыру);
2)Чукмарлы торак пункты территориясен төзеклэндерү (мэдэният йорты территориясенен тротуарын ремонтлау,мэгълүмэт стенды урнаштыру, территорияне кышкы чорда кардан чистарту,ягулык- майлау материаллары сатып алу, МТЗ-82 тракторына эленмэ жайланмалыры очен запчастьлар сатып алу);
3)Чукмарлы торак пунктында су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су жыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (су жыю манарасын ремонтлау)
4) Чукмарлы торак пунктында һәйкәлләр төзү, аларны ремонтлау (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләр булмаган) керү юлын ремонтлау) һәм аларга якын территорияне төзекләндерү (газон чапкыч өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу ).

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 220 кеше, тавыш бирудэ катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 159 кеше теркэлгэн.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларныңтавышлары түбәндәгечә бүленде: җыенда катнашкан 159 кеше «ӘЙЕ» позициясе өчен тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлегенен Чукмарлы торак пунктында узган граджаннар җыенын уздырылган, халык җыены нәтиҗәләрен – дорес дип таныргa.

2. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Чукмарлы авыл җирлеге Чукмарлы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән вакытлы хәрби хезмәт узучы, махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаилә әгъзаларыннан, 1 Төркем инвалидларыннан, көндезге уку йортлары студентларыннан тыш, 2025 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгәалынган акчаларны җибәрү " мәсьәләсе буенча карар кабул итәргә:

1)Чукмарлы торак пунктында урамнарда яктырту җайланмасы (лампаларны, энергияне сак тотучы тотучы яктырткычларны сатып алу һәм урнаштыру);

2)Чукмарлы торак пункты территориясен төзекләндерү (мәдэният йорты территориясенен тротуарын ремонтлау,мәгълүмәт стенды урнаштыру, территорияне кышкы чорда кардан чистарту,ягулык- майлау материаллары сатып алу, МТЗ-82 тракторына эленмэ жайланмалыры очен запчастьлар сатып алу);
3)Чукмарлы торак пунктында су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (су җыю манарасын ремонтлау)
4) Чукмарлы торак пунктында һәйкәлләр төзү, аларны ремонтлау (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләр) булмаган) һәм аларга якын территорияне төзекләндерү (газон чапкыч өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу һәм керү юлын ремонтлау).

3. Жыен нэтижэлэрен Чукмарлы авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Чукмарлы авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Сарман муниципаль районы
Чукмарлы авыл җирлеге башлыгы И.Х.Хадиуллин